| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ТУКТАРОВО-УРДАЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТУКТАР-УРДАЛАСЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның 31 октябре № 17

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар -Урдаласы авыл җирлегенең Карагай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Лениногорск муниципаль районының Туктар -Урдаласы авыл җирлеге Уставына таянып, Лениногорск муниципаль районының Туктар -Урдаласы авыл җирлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

2019 елның 16 ноябрендә Лениногорск муниципаль районының Урмышлы авыл җирлегенең Туктар –Урдаласы авыл җирлегенең Карагай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2020 елда Лениногорск муниципаль районының Туктар -Урдаласы авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, күп балалы гаиләләрдән (дүрт һәм аннан да күбрәк бала), Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, тыл хезмәтчәннәреннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?

- юлларга вак таш җәю
-каптажны ремонтлау.

« ӘЙЕ» «ЮК».

2. Әлеге карарны Туктар -Урдаласы авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль

районының рәсми интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://Ieninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Туктар -Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы М.М.Җиһаншин